РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«14» октябрь 2022г.

с. Тюлячи

№ 209

2023 елга Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2022 елның 29 сентябрендәге 01/1855 номерлы һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасының 2022 елның 12 октябрендәге 01-14/144 номерлы хатларын карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән 2023 елга Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә Теләче муниципаль районы белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «14» 10 2022 № 209 карары белән расланган

2023 елга Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу урыны | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар , елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 105678 |
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | авыл җирлеге | 159325 |